ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчен югалткан дип тану хакында» 29-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчен югалткан дип тану хакында» 29-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 149-VII ДС

29-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 86 (I өлеш) 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә законнарны камилләштерү максатларында эшләнгән.

Закон проекты тарафыннан «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчен югалткан дип тану тәкъдим ителә. Күрсәтелгән нормалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибен билгеләүне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең (алга таба – Ветеринария идарәсе) этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәүне гамәлгә ашыру вәкаләтен беркетүче нигезләмәләрне үз эченә ала.

Хәзерге вакытта хайваннарны тотуга «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» (алга таба – 498-ФЗ номерлы Федераль закон) 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 3 бүлегендә билгеләнгән таләпләрдә йорт хайваннарын мәҗбүри теркәү каралмаган.

Этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәүнең республика дәрәҗәсендә билгеләнгән тәртибе хуҗасыз калган этләр санын киметү һәм югалган этнең хуҗасын эзләү мәсьәләсен хәл итүгә таләп ителгән йогынтыны ясамый. Ветеринария идарәсе карамагындагы район һәм шәһәр ветеринария оешмаларында гражданнар ирекле рәвештә теркәгән этләр саны:

2017 елда – 2 862 эт;
2018 елда – 2 655 эт;
2019 елда – 4 695 эт;
2020 елда – 2 127 эт;
2021 елда – 939 эт;
2022 елда – 532 эт;
2023 елда – 65 эт.

Шул ук вакытта 2023 елда Хайваннарны тукландыру һәм иминлек үзәге сораштыру рәвешендә үткәргән Бөтенроссия хайваннарны исәпкә алу нәтиҗәләре буенча республикада 125 мең эт асрала (мәгълүмат 2024 елның 11 апрелендәге «Московский Комсомолец» электрон басмасында китерелгән), бу сан теркәлгән хайваннар саныннан шактый аерыла.

Этләрне мәҗбүри теркәү булмаганда хуҗасыз хайваннар (этләр) санын киметү мөмкин түгел.

Шул ук вакытта 498-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 8 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары йорт хайваннарын тотуга өстәмә таләпләр куярга хокуклы.

Россия Федерациясе субъектларын җайга салу практикасына анализ күрсәткәнчә, йорт хайваннарын мәҗбүри теркәү күпчелек очракта йорт хайваннарын тотуга өстәмә таләпләр кысаларында гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта Россия Федерациясенең кайбер субъектларында (Калуга, Түбән Новгород өлкәләре, Еврей автономияле өлкәсе, Краснодар крае) мәҗбүри теркәү закон акты белән каралган, Россия Федерациясенең башка субъектларында ул законга бәйле норматив хокукый актлар белән кертелгән (Киров, Мәскәү, Ленинград, Рязань, Мурманск өлкәләре, Ямал-Ненец автономияле округы, Чуваш Республикасы, Марий Эл Республикасы, Бурятия Республикасы һ. б.).

Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны урамда йөртүгә карата өстәмә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны урамда йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары (алга таба - 971 номерлы карар) белән расланды һәм 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керде.

Әлеге закон проектында каралган үзгәрешләр кертелгәннән соң республика территориясендә яшәүче этләрне 971 нче карарга тиешле таләпләр кертү юлы белән мәҗбүри теркәүне кертү планлаштырыла.

Законны кабул итү хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гамәлдәге хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттырачак, хуҗасыз этләр санын сизелерлек киметергә һәм югалган хайванның хуҗасын эзләү процедурасын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк һәм тулаем алганда хайваннарны, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәттә гражданнарның хокукларын яклауны тәэмин итүгә ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» 2014 елның 5 маендагы 298 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану таләп ителә.

Киләчәктә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны урамда йөртүгә өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карарына үзгәрешләр кертү планлаштырыла.

**«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчләрен югалткан дип тану хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.